КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 июль г.Казань № 789

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 204 нче; 2012 ел, 28 май, 425 нче; 2012 ел, 25 август, 737 нче; 2013 ел, 14 ноябрь, 874 нче; 2014 ел, 7 июнь, 389 нчы; 2016 ел, 13 август, 557 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1050 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 912 нче; 2018 ел, 12 май, 352 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 956 нчы; 2019 ел, 15 гыйнвар, 2 нче; 2019 ел, 19 июль, 605 нче; 2020 ел, 28 апрель, 344 нче; 2020 ел, 15 сентябрь, 833 нче; 2020 ел, 9 ноябрь, 1001 нче; 2021 ел, 26 февраль, 102 нче; 2021 ел, 21 июль, 623 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1139 нчы; 2022 ел, 25 июль, 714 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1011 нче; 2022 ел, 16 декабрь, 1351 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның егерме икенче абзацында «Татарстан Республикасының төрле дәрәҗәләрдәге бюджетларына» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетына» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктның бишенче абзацында «предприятиеләрдән, учреждениеләрдән» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.3 пунктта тиешле килешләрдәге «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктта «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин